СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**К А Р А Р Ы**

**« 28 » февраль 2022 ел** **№ 124**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясының 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 96 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

- Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлегенә 4 нче кушымта өстәргә (Кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы
Арча район Советы рәисе — И.Г. Нуриев

Арча район Советының
28.02.2022 ел, № 124
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге**

1) хисап чорында уздырылган планлы контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

2) хисап чорында уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

3) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

4) хисап чорында үзара хезмәттәшлектән файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында һәр контроль (күзәтчелек) чара төре буенча үзара хезмәттәшлектән файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлектән файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында аларны үткәрү нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында прокуратура органнарына контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында җибәрелгән, прокуратура органнары килештерүдән баш тарткан гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына куркынычлылык категориясенең һәрберсе буенча исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектлар саны;

16) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган контроль (күзәтчелек) чаралар уздырылган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогын бозу буенча шикаятьләр саны;

19) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) суд тәртибендә дәгъва белдерү турында җибәрелгән дәгъвалар саны;

20) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) суд тәртибендә дәгъва белдерү турында дәгъвалар саны;

21) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру таләпләрен тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны.